ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
14.10.2019

КАРАР
№ 1518

2019-2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы гражданнарын авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы муниципаль программаны раслау турында

“Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында”
2007 нче елның 21 нче июлендәге 185 номерлы Федераль законын тормышка ашыру кысаларында, "2019-2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 29 нчы мартындагы 242 нче санлы карары, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләмнәрен 2019-2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы гражданнарын авария хәлендәге торак фондыннан күчерүне тәэмин итү максатларында финанслау күләмнәре чикләрендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2025 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы гражданнарын авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы муниципаль программасын (алга таба - Программа) әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм проектлар буенча урынбасарына:
   2.1. программаны гамәлгә ашыруга торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 5 459 760,00 сум күләмендә Алабуга муниципаль районы бюджетына керүне тәэмин итәргә.
3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны бүлү һәм исәпкә алу бүлегенә:

3.1. 2019-2025 елларда төзүчеләрдән биналар алганда бирелә торган фатир мәйданнарын арттыруга чыгымнар һәм чыганаклар күләмен Министрлык белән килешенеп Программа чараларын үтәүне;

3.2. бүлеп бирелгән чараларны максатчан куллануны тәкъдим итәргә;

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче в.б. Р.М. Нуриев